وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

**Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!**

# Дин вә Мәгыйшәт

№4 (147). 27 июль 2012 / 8-рамазан-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



Дин әһелләре сәнгатьтә дә урын ала ▷2◁



Төрки әдәби дөньяны берләштерүче мотивлар ▷3◁



Кабан арты мәчете ятим балаларны кунак итте ▷4◁

# "Аллаһы Тәгалә – иң хак казый"

**Узган атнада булган вакыйгалар Татарстан мөселманнарын гына түгел, бөтен Россия мөселман өммәтен тетрәндерде. ТР мөселманнары Диния нәзарәте җитәкчелегенә һөҗүм ясалды. Илебезнең танылган мәгърифәтчеләреннән берсе булган хезмәттәшебез Вәлиулла хәзрәт Якупов вафат булды. Вәлиулла хәзрәт безнең төбәктә исламның таралуына үзеннән олуг өлеш кертеп калдырды: "Мөхәммәдия" мәдрәсәсен ачу, Апанай мәчетен торгызу, йөзләгән китап, журнал, газеталар чыгару һәм дин юлында кылган башка бик күп гамәлләрен санап китәргә була... Аллаһы Тәгалә хәзрәтебезне шушы игелекләре өчен үзенең рәхмәтенә ирештерсә, белеп һәм белмичә кылган хата-кимчелекләрен гафу кылса иде.**

Әлеге фаҗиганең ачысына карамастан, барысы да алдан Аллаһы Тәгалә тарафыннан билгеләнгән икәнен әйтеп үтәсе килә. Һәр вакыйгага Аллаһның адәм баласы гына аңлап бетерә алмаслык кодрәте салынган. Яшәешебезнең төп мәгънәсе - үзебезне Аллаһы юлына багышлау, аның рәхмәтенә ирешү өчен ихлас иманыбыз белән Аңа гыйбадәт кылу.

Рамазан-шәриф ае башланып китте, әлеге айда кылган изге гамәлләребезнең савабы җитмеш тапкырга арттырылып язылa. Шуңа да күбрәк игелекләр кылырга ашыгыйк, кылган гөнаһларыбызның ярлыкавын сорап, дога кылыйк, яхшы гамәлләрне арттырып, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешү юлында хезмәт итик.

Адәм баласы хатадан хали түгел: уйламастан, теләмичә дә бер-беребезне үпкәләтергә, кыерсытырга мөмкинбез. Мондый чакларда киң күңелле булып, гафу итәргә тиешбез. Еш кына кешеләр кайбер гамәлләрен ни эшләгәнен аңлап җиткерми яки белемсез булуы аркасында башкара. Гафу кылуда без күңел тынычлыгын табабыз, өммәтебезне ныгытып, иманыбызны саклыйбыз.

Татарстан мөфтие буларак, республикабызның мөселманнары өчен мин җавап тотам һәм, шуннан файдаланып, хокук сакчылары органнарына гаепсез мөселманнар зыян күрмәсен, нахакка гаепләнмәсен өчен тикшерү эшләрендә объектив булуны сорап мөрәҗәгать итәм. Әлеге вәхшилекне кылган затларны гафу итәм. Аллаһы Тәгалә кылган гамәлләр өчен әҗерен һәркемгә үзе бирер. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) үзенең вәгазендә әйткән: "Кешеләр кечкенә гамәлләре өчен дә, зур гамәлләре өчен дә җавап тотачаклар, беркем дә гөнаһлары өчен җаваплылыктан кача алмаячак, Аллаһы Тәгалә - иң хак казый".

Мөселман кардәшләребез, Рамазан-шәриф ае - игелекле гамәлләребезне арттырыр һәм хәйрия эшләрендә катнашыр өчен, шулай ук начар уйлардан һәм гөнаһлардан арыну, калебләребезне чистарту вакыты, чөнки Аллаһы Сөбхәнәһү вә Тәгалә әлеге изге айда кылган яхшылыклар савабын гамәл дәфтәрләребезгә арттырып яза. Нәкъ менә хәзерге вакытта без бердәмлеккә омтылырга тиешбез, бары тик шул вакытта гына Аллаһның рәхмәтенә ирешербез.

***Үзәкләшкән дини оешма –***
***ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе,***
***мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ***

## ЯҢАЛЫКЛАР

**РЕСПУБЛИКАКҮЛӘМ ИФТАР 16 АВГУСТТА УЗАЧАК**

**Республика ифтарын уздыру көне билгеле булды: ифтар 16 августта үткәреләчәк.** «Республика ифтары-2012»дә волонтёр буларак катнашырга теләүчеләрнең элемтәгә керүләрен көтәбез. Аларның **dummol@inbox.ru** электрон почтасына үзләре турында мәгълүмат (исем-фамилия, әтисенең исеме; паспорт копиясе, адрес; элемтәгә керү өчен телефон номеры) җибәрүләре сорала.

**КҮЗЛӘРЕ НАЧАР КҮРҮЧЕ МӨСЕЛМАННАР ӨЧЕН ИФТАР МӘҖЛЕСЕ ҮТТЕ**

**Казанның Ислам нуры мәчетендә ифтар мәҗлесе оештырылды.** Әлеге мәчетнең башкалардан аермасы шунда: бирегә йөрүче мәхәллә халкының күпчелеге – күзләре күрмәүчеләр. Рөстәм хәзрәт Хәйруллин хәбәр иткәнчә, ифтар мәҗлесендә Төркиядән кайткан Коръән-хафиз Сөләйман хәзрәт катнашты. Татар ашлары белән сыйланганнан соң, шәрәфле кунак гыйбадәтнең фазыйләтләре турында сөйләп үтте. Кичке аштан соң мәхәллә халкы белән тәравих намазы укылды.

**ӘЛМӘТТӘ – ИФТАР МӘҖЛЕСЛӘРЕ**

**Рамазан ае башлану белән, республикабызның күпчелек мәчетләрендә ифтар мәҗлесләре оештырыла башлады.** Әлмәт районы мөхтәсибәте хәбәр итүенчә, шушы көннәрдә районның Бигәш, Урсалы, Аксу мәчетләрендә ифтар мәҗлесләре үткәрелгән. Шәһәрнең Үзәк мәчетенә йөз иллегә якын кеше авыз ачарга йөри. Ифтар мәҗлесләренә һәр теләгән кеше килә ала.

**ЯҢА МӘЧЕТ АЧЫЛДЫ**

**Саба районының Керәнне авылында мәчет ачу тантанасы булды.** Бу көнне авылда тәүге азан әйтелде, намаз укылды. Тантананы кереш сүз белән Мичән авыл җирлеге башлыгы Айзат Гәрәев ачып җибәрде. Саба муниципаль район башлыгы аппараты җитәкчесе, районның дин эшләре кураторы Р.Сабиров, Саба муниципаль район Советы халык депутаты Т.Нәҗмиев, - мәчетнең манарасын эшләү һәм күтәрүдә ярдәм иткән ПМК-159 начальнигы Ф.Нәбиуллин, Саба җәмгыятенең 6 нчы номерлы Мичән филиалы директоры И.Дәүләтҗанов чыгыш ясады. Алга таба сүзне Саба Җәмигъ мәчете имам-хатыйбы Илдар хәзрәт Яхин алды. Аннары авыл мулласы Ясәви Гимадиевка мәчет - ачылу уңаеннан мөхтәрәм мөселман кардәшләргә, авыл халкына үзенең теләкләрен, рәхмәт сүзләрен җиткерде. Тантаналы төстә тасма киселде. Халык тәкъбир әйтеп изге йорт эченә узды. Ярты гасырдан соң, мәчет манарасыннан беренче азан әйтелде. Авылдашлар һәм кунаклар мәчет ачылу хөрмәтенә үзләренең сәдакаларын да мул итеп бирделәр, дип хәбәр итә ТР муниципаль районнары порталы.

***Мәгълүматлар***
***ТР мөселманнары Диния***
***нәзарәтенең рәсми***
***сайтыннан***
***(www.dumrt.ru) алынды***

# ИҢ ДӨРЕС УРАЗА

**Әлхәмдүлилләһи раббил галәмиин. Вәл гакыйбәтүлил мүттәкыйн. Вәссаләтү вәссәләәмү галә Мүхәммәдин вәгалә әлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн. Барлык мактауларыбыз галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһы Тәгаләгә булса иде. Расулебезнең (сгв) рух-шәрифенә дип атап әйткән салават-шәрифләребез булса иде. Һәм дә иң беренче Адәмнән (гс) алып, бүгенге көнгә хәтле килеп киткән барлык мөэмин вә мөэминәләрнең дә рух-шәрифләренә дип кылган изге догаларыбыз булса иде.**




Кадерле мөселман дин-кардәшләрем, кешеләрнең кылган гамәл вә гыйбадәтләре бертигез түгелдер. Кайбер кешеләр бер үк гыйбадәт өчен төрле микъдарда әҗер вә савап алырга мөмкиннәр. Бу кешенең ихласлылыгы вә тырышлыгы, иманның куәте вә кешенең күңелендә булган нияте белән бәйле сәбәпләр нәтиҗәсендә булырга мөмкин. Бу сәбәпләр нәкъ шулай ук ураза гыйбадәтенә дә кагыла. Ислам галимнәренең берсе булган имам Газәли хәзрәтләре үзенең китабында болай дип яза: "Кайбер кешеләр, - ди, - бары тик корсак белән җенси әгъза уразасын гына тоталар, ә икенче берәүләрнең күз, колак, кул, аяк - гомумән, бөтен тәннәре вә җаннары да уразада була. Бу ураза изгеләр уразасы саналыр вә Раббыбызга бик тә кадерле вә сөйкемле ураза булыр. Уразаның бу дәрәҗәсенә берничә шартны төгәл үтәп ирешеп була".

Иң беренче шарт - ул да булса, күз уразасы. Күз рузасы ул - карашыңны Аллабыз тыйган бөтен хәрамнардан, мәкруһлардан саклау. Күз алдыңа берәр тыелган әйбер я сурәт очраса, карашыңны төшерү шарт булып торыр. Уразаның асыл максаты да бит - кешене хәрамнардан саклау, нәфесне, шәһвәтне сындыру. Нинди мәгънә, нинди файда бар синең ач торуыңнан, әгәр син күз карашыңны хәрамнардан тыймасаң?! Пәйгамбәребез (сгв) әйтә: "Күз карашы ул - шайтанның агулы укларының берсе", - ди. Иманлы бәндә Аллабыз тыйган хәрамнарга караганда, шайтанның агулы бер угы кешенең калебенә килеп кадала да иманына һәм гыйбадәтенә зәгыйфьлек китерә. Гыйбадәт кылам дип басса, шул хәрам булган сурәт бу бәндәнең күз алдына килеп баса да гыйбадәтнең тәмен, иманның ләззәтен бетерә. Уразадан ләззәт алыйм, ахирәттә әҗерем югалмасын дисәң, бигрәк тә ураза вакытында карашыңны Раббыбыз тыйганнардан читкә юнәлт. Мәгәр Рамазанда моңа күнексәң, барча вакыт шулай булырсың.

Уразаның икенче шартларыннан берсе - ул да булса, тел рузасы. Зур бер галим әйткәнчә, иң зур изгелекләр тел белән эшләнгән кебек, иң зур гөнаһ гамәлләр дә нәкъ менә тел белән эшләнә, ди. Тел сөяксез, армый-талмый, бертуктаусыз сөйли дә сөйли. Әгәр ураза тотучы кеше телен зекер белән яисә Аллабызның изге Китабын уку белән тәрбияләп тормаса, тел шул ук вакытта гөнаһларга бик тиз кереп китә. Шул сәбәптән безнең телебез ике йозак тешләр вә иреннәр астына бикләнгән дә инде. Пәйгамбәребез (сгв) үзенең хәдисендә әйтә: "Дөрестән дә, бик күпләрнең тоткан уразалары ике әйбер, ягъни ялган белән гайбәт сәбәпле бозылды",

***(Ахыры 2 нче биттә.)***

# ИҢ ДӨРЕС УРАЗА

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

- ди. Менә күрәсезме, кардәшләрем: ураза тотып та, шул ук вакытта гайбәт сөйләп, кеше алдап булмый икән шул. Шуңа күрә мөселман кеше авызын ачканда, үзенең уразалы икәнен онытмасын, ди.

Пәйгамбәребез (сгв) әйтә: "Ураза ул - калкан", - ди. Кем дә кем уразалы булса - кычкырышмасын, оршышмасын, ди. Әгәр аңа каршы төшүчеләр булса, мин уразалы, мин ураза тотам дип җавап бирсен, диде. Бу хәдистә дә зур бер гыйбрәт вә олуг бер хикмәт бар. Ураза тотучыга кычкыра башлаганда, ул кайтарып кычкырмаса, мин уразада дисә, монда бик зур тәрбия яшерелгәндер. Ураза тотучының катылык белән, кычкыру белән җавап кайтармавы ул бит көчсезлектән түгел, аның да кычкырырга хәленнән килә, тик ул, Раббысыннан куркып, уразамның әҗере кимер, әгәр мин дә кычкыра башласам, уразам бозылыр, дип кычкырмый. Бу эштә кычкырган кешегә дә зур бер тәрбия дәресе яшерелгәндер.

Уразаның әҗерен киметмәс өчен, өченче шарт - ул да булса, колак уразасы булып тора. Бик күпләребез уразада булсак та, мин бит үзем сөйләмим, кеше сөйләгәнне генә тыңлыйм дип әйтә дә шуңа шатланып йөри. Тик бер әйберне аңламый: ялган гайбәтләр, сүз йөртүләре тыелган кебек, аларны тыңлавы да хәрам булды, бигрәк тә ураза тотучы кешеләргә. Раббыбыз үзенең Китабында әйтә: "Ссәммәгунә лил кәзиби әккәлунә лиссухт", ялган сүзләр тыңлаучы кеше, көне буе ураза тотып та, хәрам ризык белән авыз ачучы, ифтар кылучы кебек булыр, ди. Күз алдына китерегез инде: уразаңнан күпме әҗер калыр соң?! Пәйгамбәребез (сгв) әйтә: "Әгәр син ялган, я гайбәт сөйләгәнне тыңлап утырып, шуңа риза булсаң, сөйләүче кеше кебек нәкъ шундый ук гөнаһлы булырсың", - ди. Димәк, син кардәшең хакында гайбәт сөйләүне ишетсәң - туктатырга тырыш, әгәр туктата алмасаң - тыңлама, китеп бар. Әбу Дәрда (рг) әйтә: "Кем дә кем үзенең кардәшенең дәрәҗәсен кимсетүдән борылса, Аллабыз ул бәндәнең йөзен Кыямәт көнендә уттан борыр", - диде. Икенче бер сәхабә Җәбир (рг) әйтә: "Әгәр син ураза тотсаң, синең телең, күзең, колакларың гайбәттән, ялганнардан имин булсын, алар да уразалы булсын, күршеләреңне газаплаудан саклан, сиңа иминлек килер, уразасыз көнең белән уразалы вакытыңны бер итмә", - ди.

Уразаның әҗерен саклау өчен, дүртенче шарт - ул да булса, калган бөтен әгъзаларны хәрамнардан, шөбһәле нәрсәләрдән саклау. Нинди файда синең көне буе ураза тотып та, ифтар вакытында шөбһәле булган, яки хәрам ризыклар ашалса, бу - шәһәр җимереп, шул җимерекләрдән бина салу кебектер. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) әйтә: ураза тотучылылар арасында күпме бәндәләрнең, Раббылары каршысында ач торып, кибегеп бетүләреннән башка һичбер әҗерләре калмады, ди. Бу - әлбәттә, гайбәт, ялган сөйләүчеләр,тыңлаучылар, хәрам белән авыз ачучылар.

Уразаның әҗерен саклый торган бишенче шарт - ул да булса, артык күп ашаудан тыелудыр. Имам Газәли хәзрәтләре әйтә: "Хәләл ризык ул дәва кебектер, аның әзе файдалы булса, күбе, артыгы зарардыр", - ди. Пәйгамбәребез (сгв) әйтә: "Аллаһы Тәгаләнең иң яратмаганы - адәм баласының тутырылган капчыклар кебек тулы корсагы", - ди. Ураза дигән гыйбадәтнең асылы - шайтан юллары булган шәһвәт юлларын ябу, адәм баласының шәһвәтен сындыру. Ә син, көне буе ач торып, зәгыйфьләнгән тәнеңне яңадан тутырып куйсаң, бөтен шәһвәтең кире уяна да инде. Шуңа күрә ураза тотучы кеше күп ашаудан тыелырга тиешле булыр. Күп ашау уразаны бозмаса да, әҗерен киметер.

Уразаның әҗерен саклый торган алтынчы шарт - ул да булса, күп йоклаудан саклану. Әгәр ураза тотучы бәндә бөтен ураза көнен йокыда үткәрсә, ул уразаның бер авырлыгын да күрмәячәк, авырлыгын күрмәгәч, тәненә бер авырлык та килми, зәгыйфьлек тә килми, бәндәнең калебе, җаны чистармаячак. Расулебез (сгв) бер хәдисендә әйтә: "Ураза ул - әманәт, шуңа күрә һәр иманлы кеше үз әманәтен сакласын", - ди.

Раббым, барыбызны да корсак белән җенес әгъзасы рузасы тотудан сакласаң иде. Бөтен тәнебез белән, калебебез белән, җаныбыз белән уразада булып, Аллабызның рәхмәтенә ирешеп, җәннәтләргә керергә насыйп булса иде. Ярабби, Ходаем!

***Алмаз хәзрәт ШӘРИФУЛЛИН,***
***Татарстанның көньяк төбәге казые,***
***Чистай районы имам-мөхтәсибе***

# Дин әһелләре сәнгатьтә дә урын ала

**Әйе, Аллага шөкер, динебезгә иляһи караш, дин әһелләренең якты образлары акрынлап әдәбиятка һәм сәнгать мәйданына кайта.**

Динебезне яклауның милләтебезне яшәтүдә көчле бер чара булуы турында Гаяз Исхакый бик ачык итеп әйткән: “Әүвәл әхлак бозыла, икенче, дин бетә, өченчедән, ул халык үзе бетә”, дип яза ул. Шуңа да динебезне зурлау, мулла, мөәзиннәрнең уңай образларын сурәтләү XX гасыр башы татар әдәбиятында билгеле бер дәрәҗәдә чагылышын тапты. Без аны шигъриятебездә, Гаяз Исхакый прозасында күрәбез. Әмма совет чорында әдәбиятта да, сәнгатьтә дә дин әһелләре асылда гел дә тискәре сурәтләнешен тапты. Коммунистлар партиясенең дингә каршы алып барган пропагандасы да тәэсир итми калмады.



Һәм менә, ниһаять, иркенлек җилләре исә башлау белән дингә традицион уңай караш акрынлап үз урынын ала, әдәбиятта һәм сәнгатьтә дә дин әһелләренең якты образлары пәйда була башлады. Без моны күренекле язучыбыз Туфан Миңнуллин драматургиясендә дә күрәбез. Мөселман диненең милләтебез язмышында уйнаган роле турында ул “Илгизәр плюс Вера” пьесасында, “Шәҗәрә” исемле драматик хикәясендә яктырта башлады. Беренче әсәрдә катнаш никахларның татар милләте өчен зыян салуы ачык итеп куела. Икенче пьесада патша хакимияте чорындагы көчләп чукындыруның аянычлы корбанына әйләнгән Владимир Васильевич Сәетбәков образы бирелә. Бу кешедә үз милләтеннән ваз кичү, алай гына да түгел, аңардан хурлану, татар булуын ничек тә яшерергә тырышу ныклы тамыр җибәргән. Мондыйларда халкыбызның алдынгы катламнарыннан берсе булган морзалар нәселенең электән килгән күренекле сыйфатларын җуя баруы гәүдәләнә. Авторның “Сөяркә” (икенче исеме “Гөнаһсыз гөнаһлылар”) драматик хикәясендә үзгәртеп корулар чорында илдәге демократик иркенлекләрнең беренче чагылышы булган күренешне – динебезгә әйләнеп кайтуның рухи чистарынуларга алып килүдәге көче үзенчәлекле төстә сурәтләнә. Шундый әсәрләре аша Т.Миңнуллин дин әһеленең тулы канлы, бербөтен образын тасвирлауга килде. Бу – аның “Мулла” исемле драмасындагы Әсфәндияр образы.

Гадәттә без муллаларны олы яшьтә, карт кеше кыяфәтендә күрергә өметләнәбез. Муллалар, хәзрәтләр тормыш тәҗрибәсе туплаган кешеләр булып күзалланалар. Т.Миңнуллинның мулласы әле генә мәдрәсә тәмамлаган 22 яшьлек буйдак егет. Әсфәндиярның тормыш тәҗрибәсе дә, дин юлында күрсәткән хезмәте дә әлегә юк. Хәер, аны бөтенләй дә тормыш михнәтләрен күрмәгән дип әйтеп булмый. Малайлык юләрлеге белән законсыз эш эшләп ул 12 яшендә төрмәдә утырып чыккан, төрмә кануннарын яхшы белә, көчкә каршы көч тә куллана ала. Шуңа да ул төрмәдә утырып кайткан, бандитлык шөгыльләре белән авылны куркытып торучы Эльбрус кебекләрдән шүрләми, андыйларга, аларның ук ысулларын кулланып, каршы тора ала. Ләкин аракы исереклегенә бата барган авылны дин юлына бастыру өчен аңа болар гына җитмәс иде, билгеле. Дин кануннарын яхшы белүе, иң четерекле вакытларда да үз тормышында аларга тугрылыклы булып кала белүе белән ул акрынлап хөрмәт казана, Вәлиәхмәт кебек, Әмир, Налимә кебекләрне акрынлап туры юлга чыгара. Иң мөһиме, ул мөслиммөслимәләр юлына чыгаруда башлангыч итеп Мөслимә карчыкның шәһәрдән авылга кайткан оныклары Илдар, Вилдан, Илдария кебек, әле күңелләре бозылмаган яшүсмерләрне һәм балаларны ала. Аларга дин сабаклары бирә, алмаш әзерли. Һәм әсәрнең тәмамлануы да бик мәгънәле: соңгы күренештә Әсфәндияр “намаз вакыты җитте, азан әйтергә кирәк” дип җыенганда, “шул вакыт азан әйткән тавыш ишетелә”. Моны Мөслимә карчыкның өлкән оныгы, Әсфәндиярның шәкерте Илдар әйтә икән... Әйе, дин югалмый, югалмаячак, Әсфәндиярларның, Илдарларның юлы дәвам итәчәк, ныгыячак!

Драмада тагын да бер яңалык бар. Соңгы вакытта әдәбиятта һәм сәнгатьтә эшмәкәрләрне, ягъни бизнесменнарны гадәттә каралтып сурәтләү урын алды. Т.Миңнуллин үзенең “Сөяркә” исемле психологик драмасында эшмәкәрне кайбер уңай сыйфатлары белән тасвирлаган образ биргән иде инде. “Мулла” әсәрендә Самат исемле бизнесмен образы бу яктан тагын да алгарак китеш булды. Бу кеше авылда мәчет салдыра. Әмма мәчеткә йөрүчеләрнең булмавы, авылдашларының торган саен аракы сөременә буяла барганын күреп, ул, яшь шәкертне күндереп, авылга алып кайта, аңа әтиләренең өен бирә, һәрьяклап ярдәм итеп тора. Шундый таянычы булмаса, Әсфәндияр, бәлкем, бу авылда озак түзеп тора алмас та иде...

Күренекле драматург Туфан Миңнуллинның яңалык рухы белән сугарылган бу әсәре театрларыбыз тарафыннан хуплап каршы алынды. Ул Татарстан һәм Башкортстан сәхнәләрендә ныклы урын били, тамашачыларның хуплавы астында уйнала.

***Азат ӘХМӘДУЛЛИН,***
***филология фәннәре докторы, профессор***

## Кем дә кем кешене үз ихтыяры белән үтерсә...

**Узган атнада республикабызда коточкыч хәлләр булды. Шуңа бәйле рәвештә Коръәндәге "Ән-Ниса (Хатыннар)" сүрәсенең 93 нче аятенә мөрәҗәгать итәсем килә: "Кем дә кем мәкер белән мөселманны үтерсә, эчләрендә дөрләп ут янган җәһәннәм аның җәзасыдыр. Ул анда мәңге калачак. Аллаһ аңа газап бирер, ләгънәт орыр вә аның өчен авыр җәза әзерләр".**

Бу аятьтә Аллаһы Тәгалә кеше үтерүчеләргә бик куркыныч җәзалар вәгъдә итә: җәһәннәм, Үзенең каргышын һәм күтәрә алмаслык җәзаларны. Ибн Габбас бу турыда болай дигән: "Аллаһы Тәгаләгә тиңдәшлек тоту һәм кеше үтерү - иң зур гөнаһтыр". Башкача әйткәндә, кеше үтерү потларга табыну белән бер рәткә куелган. Рәсүлебез (сгв) хәдисләренең берсендә, Кыямәт көнендә иң беренче булып, коелган кан буенча хөкем чыгарылачагы турында әйтелә.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, без бу җинаятьне кем эшләгәнен белмибез, ләкин мөселман һәм Татарстан өммәте өчен кайгырган кеше буларак, сезгә мөрәҗәгать итәсем килә: бу аятьнең мәгънәсе турында уйланыйк. Кеше гомеренең кыймматe көннән-көн кими барган заманда яшәвебезгә карамастан (Ливия, Сүрия кебек илләрдә булып үткән вакыйгалар моңа дәлил булып тора), хайваннар дәрәҗәсенә төшмик, кеше була белик, мөэминнәр булып калыйк. Безнең дан-шөһрәтләр артыннан куубыз да, тормышка карашларыбыз да, байлыгыбыз да Җәһәннәмнең мәңгелек утында янууга тормыйлар.

Югарыда китерелгән аятьне аңлатып, Ибн Габбас мөселман кешесен үтерүчегә бернинди тәүбәгә килү булмаячагы турында әйтә. Шулай да, мөселманнарга кемне дә булса каргау килешми, шуңа күрә вафат булучыларга багышлап догалар кылыйк һәм Аллаһы Тәгаләдән үтерүчеләрне (аларның мөселман яки мөселман булмауларына карамастан) туры юлга бастыруын һәм чын күңелдән тәүбәгә китерүен сорыйк. Кеше үтерү гөнаһын Җәһәннәмнең мәңгелек уты белән чагыштырып булмый.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, Вәлиулла хәзрәтне үтерүчеләр мөфтигә генә түгел, ә Татарстанның барлык мөселманнарына да зыян китерделәр. Алар безнең җәмгыятькә каршы килделәр. Шул сәбәпле хәзер тентүләр һәм сорау алулар бара. Моңа сабырлык һәм тотнаклык белән карыйк, чөнки "Фетнә чыгу үтерүдән начаррак". Хокук саклау органнары алып барган эшне аңлап була. Монда иң элек профилактика эшен күрергә кирәк. Үзган атнадагы фаҗигале вакыйгалар аларны гына түгел, барыбызны да бу проблемага башкача карарга мәҗбүр итте. Мөселман өммәтендә булган хәлне аңлар өчен вакыт кирәк.

Аллаһы Тәгалә бу Рамазан аен имин итсен, фаҗигаләрдән һәм бәлаказалардан сакласын, тоткан уразаларыбызны кабул итсен. Я Раббым, Татарстан мөселманнарына акыл, сабырлык, бердәмлек, тотрыклылык һәм озак елларга иминлек бир! Амин.

**Габдулла хәзрәт ӘДҺӘМОВ,**
**ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең беренче урынбасары**


ООО «Ритуальные услуги»
Изготовление памятников и оград

ул. К.Насыри, 17, мечеть Аль-Марджани,
ул. 2-я Армавирская мечеть Нур-эль-Ислам,
ул. Мусина, 10, мечеть Булгар,
ул. Чистопольская, 1, мечеть Казан Нуры,
Оренбургский тракт, 193, мечеть Гадель,
ул. Мавлютова, 48, мечеть Ризван,
ул. Фучика, 52, мечеть Хузейфа,

Понедельник - пятница - с 9:00 до 18:00,
суббота - с 9:00 до 13:00.
**Тел.: 225-28-90, 293-25-61**

Основное производство находится на мусульманском кладбище при мечети Аль-Марджани на Мамадышском тракте.
Понедельник - с 9:00 до 13:00, со среды по воскресенье - с 9:00 до 18:00,
вторник - выходной.
**Тел.: 225-28-90, 293-45-93**

**На мусульманском кладбище захоронения ведутся по канонам Шариата. Тел. 297-28-90**

Реклама

# ТӨРКИ ӘДӘБИ ДӨНЬЯНЫ БЕРЛӘШТЕРҮЧЕ МОТИВЛАР

**Бүгенге көндә төрки дөнья эчтәлек һәм форма ягыннан гаять күпкырлы, күпмилләтле. Хәзерге вакытта рәсми рәвештә теркәлгән егерме алты төрки милләт турында сүз алып барырга мөмкин.**

| | | |
|---|---|---|
| 1.Үзбәк | 10. Якут | 19.Хакас |
| 2.Казакъ | 11.Кумык | 20.Ногай |
| 3.Әзербайҗан | 12.Кырым татары | 21.Алтай |
| 4.Татар | 13.Уйгур | 22.Шор |
| 5.Төрекмән | 14.Төрек | 23. Долган |
| 6.Кыргыз | 15.Тува | 24.Караим |
| 7.Чуваш | 16.Гагауз | 25.Кырымчак |
| 8.Башкорт | 17.Карачай | 26.Тофалар |
| 9.Каракалпак | 18.Балкар | 27. Һ. б. |

Хәзерге вакытта төрки халыклар бер-берсенән сөйләм теле, аерым гореф-гадәтләре, мәдәни һәм сәяси дөньялары белән аерылып тора. Барлык төркиләрнең культурасы бик борынгы дәверләрдә үк формалашкан уртак мәдәни катламнан күтәрелә. Туганлыкны тәшкил итүче, бүгенге көнгә кадәр уртаклыкны саклап килүче күпсанлы берләштерүче мотив-факторларны күрсәтергә мөмкин. Шуларның иң мөһимнәренә тукталып үтик.

Бердәмлекнең нигезен тәшкил итүче, төркиләрне төрки дип таныткан фактор ул - төрки тел. Шуңа күрә, без тел өлкәсендәге уртаклыкка иң беренче чиратта игътибар итәбез. Гомумән, зыялы төрки дөнья XIX йөзгә хәтле бер әдәби тел кысалары эчендә яши. Моны без бөтен төрки дөнья буенча сәяхәт итүче китаплар язмышыннан күрәбез. Мәсәлән, бер төбәктә иҗат итүче төрки әдипнең әсәрләре, меңәрчә километрлар ераклыкта урнашкан икенче төбәктә яшәүче укымышлылар өчен аңлаешлы һәм якын була. Ул китаплар ике төбәкнең дә халыклары арасында тарала, яратылып укыла, кат-кат кулдан күчерелә. Әйтик, Идел буйларында яшәүче болгар әдибе Кол Галинең, Кече Азиядәге төрек әдипләре Ашуг-пашаның һәм Әхмәд Чәләбинең, шулай ук Урта Азия җирлегендә яшәүче үзбәк шагыйрьләре Һөвәйдә белән Навоинең, Кавказ төбәгендәге әзәрбайҗан язучылары Физули һәм Нәсиминең, Азиянең иркен далаларында яшәүче казакъ сүз остасы Абай белән төрекмәнле Мәхтүмколиның һәм башка танылган төрки әдипләрнең лирик әсәрләре бөтен төрки дөнья буенча киң таралган була. Татар галимнәре М.Госманов, Х.Миңнегулов үзләренең хезмәтләрендә бу мәсьәләгә аерым тукталалар.

Әйе, бүгенге көндә сөйләм телебез дә, әдәби телебез дә мөстәкыйль, алар арасында шактый аерма бар. Арабызда гасырлар ята бит. Әмма генетик һәм этник якынлыкның мөһим элементын тәшкил иткән тел якынлыгы элекке дәверләрдән алып хәзергә кадәр сакланып килә. Аерым гипотезаларга таянсак, берничә мең ел үтүенә карамастан, шул ата-баба теле безне берләштереп тота.

Икенче берләштерүче фактор - гомумтөрки матди һәм рухи культура ядкарьләре. Төрки халыкларның этнография, гореф-гадәт, йола-канун өлкәсендә дә охшашлыклар җитәрлек. Шулай да без әдәбиятка якын өлкәгә күз салыйк. Уртак мифология җирлегендә барлыкка килгән фольклор, ә соңыннан язма әдәбият әсәрләре дә үзләрендә күпсанлы игезәк сюжетлар, образлар саклыйлар. Шуларның иң популяр, иң еш очрый торганнары: Күк-Тәңре, Җидегән йолдыз, Алып батыр, Ак бүре, Акбүз ат, Тулпар ат кебекләрне санап үтәргә мөмкин.

Төрки каганат, Дәшти Кыпчак (Кыпчаклар даласы), Алтын Урда кебек төрле-төрле төрки кавемнәрне берләштергән зур дәүләт, уртак мәдәният системасында яшәү төркиләрнең уртак әдәбият нигезләре формалашуына төп сәбәп була. Бу якынлыкны без, иң әүвәл, халык авыз иҗаты әсәрләре буенча гасырлар буе халык теленнән төшмичә, онытылмыйча сакланып калган күпсанлы дастан-кыйссаларда, әкият-мәзәкләрдә, әйтем-мәкальләрдә күрәбез. Мәсәлән, "Алпамыш", "Идегәй", "Гёр-оглы", "Китаби дәдәм Коркот", "Угызнамә" кебек героик-романтик һәм "Йосыф-Зөләйха", "Таһир-Зөһрә", "Ләйлә-Мәҗнүн" кебек мәхәббәт-романтик дастаннар күпсанлы төрки милләтләр өчен уртак. Шулай ук төрки фольклорда хатын-кыз алыплар, хатын-кыз сугышчылар турындагы сюжетларның киң таралган булуын да искә алырга кирәк. Гомумән, борынгы төрки дөньяда хатын-кыз ирләр белән бер дәрәҗәдә хөрмәт ителгән. Алар ирләр белән беррәттән атка утырып яу чапкан, дәүләт белән идарә иткән. Амазонкалар, ягъни сугышчы алып хатын-кызлар турындагы хәбәрләр антик тарихчыларда ук очрый. Алар амазонкалар яшәгән урынны Кече Азия, Кавказ, Скифия җирләре дип күрсәтәләр. Ә бу исә сармат, массагут, саклар, кыпчаклар кебек төрки кабиләләрнең яшәгән урыны. Соңга таба бу мәгълүматлар гарәп сәяхәтчесе хезмәтләрендә, мисалга Ибне Батута сәяхәтнамәсендә дөнья күрә. Амазонкалар турындагы сюжетлар, аларның образлары "Айсылу һәм Көнбатыр", "Кырык кыз" дастаннарында, "Алпамыш" эпосының фрагментларында гүзәл гәүдәләнеш таба. Әлбәттә, уртак фольклор образлар турында сүз алып барганда, аеруча популяр булган, үзендә халык акылын, тапкырлыгын туплаган Хуҗа Насретдин образын да атап әйтү кирәк. Төрки халыкларда халык шагыйрьләре традицияләре дә көчле була. Сүз чичән, ашуг, бахши, акын, манасчы кебек жырау-шагыйрьләрнең остазлык мәктәбе турында бара.

Инде фольклордан язма әдәбият катламына күтәрелсәк, аның тарихи тамырларының гомумтөрки язма ядкарьләр җирлегенә барып тоташканын күрербез. Ә бу V-VI гасырларга караган рун әлифбасында язылган Орхон-Енисей язмаларында, X-XI гасырларда Мәхмүт Кашгари, Йосыф Баласагунлы, Әхмәд Йүгнәкиләр тарафыннан язылган фәнни хезмәтләрдә, этик-дидактик поэмаларда чагыла.

Өченчедән, төрки дөньяны бердәм итеп тотучы, мәдәниятебездә дә, әдәбиятыбызда да якынлык тудыручы гамәл - ул безнең тарихи хәтеребез, ягъни уртак тарихи үткәнебез.

Рәсми фән буенча төркиләрнең тарихи ватаны булып Евразия континенты санала. Төркиләр безнең эраның беренче гасырларыннан ук бөтен континент буенча тарала башлыйлар. Безнең эраның IV гасырларында исә Европаның үзәк регионнарына хәтле барып җитеп, бөек Атилла җитәкчелегендә гуннар империясен төзиләр. Европа, Азия киңлекләрендә төрки бабаларыбыз борынгы цивилизацияләр белән аралашып, гореф-гадәт, мәдәният алмашып, аларга да үз өлешләрен кертеп, үзләрен башка халыклар белән тиң тоеп яшиләр. Ерак Көнчыгышта Монголия далаларыннан һәм Бөек Кытай диварларыннан алып, Көнбатышта Европаның үзәгендә аккан Дунай елгасына хәтле җәелеп яткан Евразия далалары аларның уртак ватанына әверелә. Аермалы сыйфат буларак, төрки халыкларның тормышы һәрвакытта оешкан, үзәкләштерелгән дәүләт системасы кысаларында үтүен билгеләргә кирәк. Даими рәвештә зур көчле дәүләтләр төзелә, югары үсешле мәдәниятләр булдырыла. Һәр яңа дәүләт варислык принцибы нигезендә үсә. Бөек Төрки каганат, Хәзәр каганаты, Уйгур каганаты, Бөек Болгар каганаты, Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда дәүләте, Казан ханлыгы, Мәмлүкләр дәүләте, Сәлҗүкләр империясе, Бөек Госманлы империя һәм башкалар әнә шуның ачык мисаллары. Тарихи закончалык нигезендә таркалган дәүләт урынына аның варисы булып икенче бер дәүләт барлыкка килә һәм берсенең мәдәни казанышлары икенчесенә нигез, яңа мәдәни үсеш өчен эттәргеч булып тора. Шул рәвешле, канлы сугышлар, зур югалтулар булуына да карамастан, төрки мәдәниятләрнең өзелмәс чылбыры барлыкка килә, тарихи хәтер буыннан буынга күчеп саклана килә.

Әмма шуны да ассызыклап үтәргә кирәк: бүгенге көндә төркиләрнең тарихына, культурасына карата яңадан-яңа ачышлар ясала. Нурихан Фәттахның "Шәҗәрә", Дефак Рахматинең "Дети Атлантиды", Олжас Сөләйманованың "АзиЯ", Адилә Айдәнең "Этрусклар төрек идеме?" китаплары шул гипотезаларга багышланган.

Әлеге фәнни гипотезалар буенча төркиләрнең тарихи ватаны итеп Евразия континенты түгел, ә борынгы цивилизацияләрнең бишеге - Урта диңгез бассейны карала.

Биредә туган борынгы цивилизацияләр үсешендә төрки бабаларыбыз турыдан-туры катнашкан, хәлиткеч роль уйнаган, дип карала. Галимнәр фикеренчә, әле бүгенге көндә дә төркиләр тормышында - телдә, милли костюм, архетектура, халык авыз иҗаты, гореф-гадәтләр, топонимикада шул борынгы культураның билгеләре саклана. Нинди цивилизацияләр турында сүз бара соң? Б. э. к. III-II меңьеллыкка караган, җидесу җирлегендә урнашкан Шумер цивилизациясе турында. Күрәсең, "Тарих шумердан башлана" дип, юкка гына әйтми галимнәр. Әйе, югары культураның төп билгеләре булган язу системасы, бай китапханәләр, астрономия, тыйб (медицина), математика өлкәләренә караган хезмәтләр, әдәби текстлар монда беренче тапкыр барлыкка килә. Аның варисы булып каралырлык Бабиле дәүләте культурасы; данлыклы борынгы грек цивилизациясе үсешендә зур роль уйнаган Крит утравы, Эгей архипелагы һәм континенталь Греция җирлегендә урнашкан Крит-Миной культурасы. Крит утравының, Фест шәһәрендә табылган спираль эзлеклегендәге тамгалар урнашкан түгәрәк балчык пластинка-дисбене Нурихан Фәттах төрки телдә укыды. Бу вакыйга барыбызда да зур кызыксыну уяткан иде. Аерым алганда, Борынгы Мисыр культурасы белән дә уртаклык бар дип карала. Сөннәр (һуннар, гуннар) культурасы белән чагыштырганда бу якынлык аеруча ачык күренә икән. Шулай ук латин халкы белән берлектә Рим империясен төзүдә катнашкан этрусклар (тирсеннар, тусклар), саба халыкларының культурасы да борынгы төркиләрнең культурасы булырга тиеш дигән фараз бар. Бу очракта латин, һәм борынгы грек телендә төрки алынмаларның күпләп очравы, аерым әдәби әсәрләр сюжетында охшаш детальләрнең күзгә ташлануы (Ана бүренең ике ятим баланы имезем үстерүе) әнә шул борынгы дәверләрдән килгән тыгыз элемтәләрнең нәтиҗәсе дип карала.

Фәнни гипотезалар төркиләрнең эзе Америка континентында да булганын күрсәтә. Америка индеецларының Сиудакота, Темуча, Майя һ. б. кабиләләре телләренең төрки лексикадан торган булуы ачыклана. Бу ачышлар тарихы XIX гасырда Отто Рериг хезмәтләреннән башлана һәм алар И.Хәлфинга язылган хатта ачык күренә, XX гасырда Ә.Кәримуллин бу гипотезаны күтәреп ала, үстереп җибәрә.

Уртак дини вәзгыятьнең дә мәдәни, әдәби якынлыкта зур роль уйнаганы күренә. Билгеле булганча, әүвәлге этапта барлык төркиләр дә тәңречелек динендә булалар. Иң югары кодрәт иясе итеп Күк-Тәңрене таныйлар. Шуның белән бергә кояшны изгеләштерү, аңа табынуны да искә алыйк. VII-VIII гасырларда төркиләр арасында ислам дине тарала башлау белән бәйле рәвештә яңа этап башлана. Төрки халыкларның дөньяга карашларында, гореф-гадәтләрендә, мәдәниятләрендә тирән үзгәрешләр туа. Язма әдәбиятта да бераллачылык фәлсәфәсе, мөселман каһарманнарына, пәйгамбәрләр язмышына мөрәҗәгать итүне, Коръәни сюжетларны күпләп файдалануны күрәбез.

Язма әдәбият традицияләренә зур тәэсир ясаган Шәрык әдәбияты традицияләрен аерым карарга кирәк. Гомумән, шәрык-мөселман цивилизациясен үстерүдә гарәпләр, фарсылар белән берлектә төркиләр дә зур әһәмияткә ия. Әйтик, Әл-Фәраби, Низами, Навои, Бабур, Физули, Нәсими кебек чыгышы белән төрки булган зыялылар шәрык культурасының күренекле вәкилләре булып санала. Төрки патшаларның сараенда фарсы поэзиясе, гарәп фәне чәчәк атканын да онытмыйк. Көнчыгыш илләргә әдип хезмәтен аерым һөнәр (профессия) итеп билгеләү хас түгел. Бу күренеш бары тик шәрык культурасы өчен (яки алар белән тыгыз мөнәсәбәтләрдә торган культуралар өчен) характерлы. Әйтик, Мәхмүт Газнави исемле төрки хөкемдарның сараенда дүрт йөзләп шагыйрь яши, иҗат итә. Төньяк Һиндстанда Бөек Маголлар империясенә нигез салучы Мөхәммәд Зәхәреддин Бабур, патша булу белән беррәттән галим, шагыйрь буларак та таныла. Гомумән, шәрыкта, шул исәптән төркиләрдә дә шагыйрь булу ул аерым дәрәҗә булып санала. Шагыйрь кешегә хәким, ягъни гыйлем иясе дип эндәшәләр. Чөнки шагыйрь булып танылганчы ул, иң әүвәл төрле фәннәрдән югары белем алырга, үзеннән алда яшәгән классикларны яттан белергә тиеш була.

Дөрес, төркиләрнең дә мәдәнияте үсешендә гарәп-фарсы цивилизациясе зур роль уйный. Иң элек, һәр татар зыялысы өч тел: дин һәм фән теле булган гарәп телен, поэзия теле булган фарсы телен, туган теле булган төрки телне белергә тиеш дип саналганын искә алыйк. Фирдәүси, Рудакый, Низами, Хафиз, Сәгъди, Гомәр Хәйям кебек шәрык әдәбияты классиклары төрки әдипләр өчен остаз булып торалар. Гарәп-фарсы әдәбиятыннан төрки поэзиягә жанрлар системасы, гаруз шигырь метрикасы, күпсанлы сюжет-мотивлар, образ-сурәтләр күчә. Мәсәлән: "Хәсрәү Ширин", "Ләйлә вә Мәҗнүн" сюжетлары, Искәндәр Зөлкәрнәйен, Ибраһим Әдһәм, Локман Хәким, Нәүширвал образлары һ. б. Төрки әдәбият эстетикасына суфичылык идеологиясе, ә әдәби телгә гарәп-фарсы теленең дә йогынтысы зур булуын ассызыклыйк. Шуны да онытмыйк, төркиләр арасында хронологик дәвамчылык ягыннан иң озак кулланылган һәм географик таралу ягыннан иң киң таралганы - гарәп әлифбасы була. Ерак Көнчыгышта Төркестан җирләреннән алып Көнбатышта Идел-Урал төбәгенә хәтле киң территориядә мең елдан артык бер дәвердә гарәп язуы төрки халыкларга, шул исәптән татарларга хезмәт иткән.

Төрки милләтләрнең мәдәниятенә караган бу үзенчәлекләр бүгенге көндә дә төрки дөньяның бердәмлеген саклый.

***Раушания ШӘФИГУЛЛИНА,***
***филология фәннәре кандидаты***



# Рәхмәтемне белдерәм!

**Хөрмәтле дин кардәшләрем, милләттәшләрем, туганнарым, дус-иш мәхәлләдәшләрем!**

Мөхтәрәм мөфти Илдус хәзрәт Фәиз һәм ТР мөселманнары Диния нәзарәте хезмәткәрләре, республикабызның, шәһәребезнең дәүләт җитәкчеләре!

Минем 80 яшьлек юбилеемны шушылай зурлап билгеләп үткәнегез өчен барыгызга да Аллаһы Тәгаләнең бәрәкәте һәм рәхмәте булсын. Бик күңелле кичә узды. Анда минем якын туганнарым, шәкертләрем, хезмәттәшләрем катнашты. Зур-зур бүләкләр тапшырдылар, үзләренең матур теләкләрен җиткерделәр. Казый Сөләйман хәзрәт Зарипов мөфтиятнең "Халкыбызга фидакарь хезмәт өчен" медален тапшырды. Өлкән кешене шулай хөрмәтләвегез бәрабәренә Аллаһы Тәгалә сезне Үзенең мәрхәмәтеннән ташламасын. Киләчәктә дә бергә-бергә эшләрбез, халкыбызга хезмәт итәрбез дигән теләктә калам.

Илдус хәзрәтнең тизрәк савыгып, изге хезмәтенә керешүенә өметләнеп, мәхәлләбез белән изге догада калабыз. Шушы фани дөньяда Аллаһы Раббыбызның ризалыгына ирешеп, ахирәттә Аның рәхмәтенә лаек булсак иде дигән изге теләк белән,

**Гыйльмулла хәзрәт хаҗи-әкбәр,**
**Мәдинә мәчете имам-хатыйбы**

## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Сәхәр тәмамлана | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 28.07.12 | 2:41 | 3:11 | 4:41 | 13:02 | 18:19 | 20:57 | 22:27 |
| Якшәмбе | 29.07.12 | 2:43 | 3:13 | 4:43 | 13:02 | 18:17 | 20:55 | 22:25 |
| Дүшәмбе | 30.07.12 | 2:45 | 3:15 | 4:45 | 13:02 | 18:16 | 20:53 | 22:23 |
| Сишәмбе | 31.07.12 | 2:47 | 3:17 | 4:47 | 13:02 | 18:15 | 20:51 | 22:21 |
| Чәршәмбе | 1.08.12 | 2:49 | 3:19 | 4:49 | 13:02 | 18:13 | 20:49 | 22:19 |
| Пәнҗешәмбе | 2.08.12 | 2:51 | 3:21 | 4:51 | 13:02 | 18:12 | 20:47 | 22:17 |
| Җомга | 3.08.12 | 2:53 | 3:23 | 4:53 | 13:02 | 18:11 | 20:45 | 22:15 |
| Шимбә | 4.08.12 | 2:55 | 3:25 | 4:55 | 13:02 | 18:09 | 20:43 | 22:13 |




БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ!

# Кояш юк – көн юк, көн юк – тереклек юк



**Галәмдә чиксез күп системалар хәрәкәт итә. Аллаһ аларның һәрберсен дә контрольдә тота, ләкин без аны сизмәскә дә мөмкин. Аллаһы Тәгалә Галәмне бик нечкәләп, вак-төякләренә дә игътибар итеп яралткан. Ул аны кешеләр Галәмнең чиксез кодрәтенә ышансыннар өчен шулай эшләгән.**

АЛЛАҺЫ Тәгалә Коръәндә кешеләргә мөрәҗәгать итеп, Галәмне яратуының сәбәпләрен әйтә: "Аллаһ - җиде кат Күкне вә шулар санында ук Җирне яралткан Раббы. (Аллаһның) фәрманнары шулар арасыннан иңеп тора. Шулай итеп, Аллаһның бөтен нәрсәгә кодрәте җиткәнлеген вә һәр нәрсәне гыйлеме белән урап алганын беләсез" ("Талак" сүрәсе, 12 нче аять).

Галәмнең башы да, азагы да юк икәнлекне барыбыз да белә. Без аның чынбарлыкта булган үлчәмнәрен күз алдына да китерә алмыйбыз.

Кояшның диаметры Җирнең диаметрыннан якынча 103 тапкыр зуррак. Әгәр Җир йөзем җимеше кадәр булса, ә Кояш без белгән гади футбол тубыннан да 2 тапкыр зуррак була. Алар арасындагы ераклык та кызыксыну уята. Нәкъ галәмдәгечә булсын өчен тупны (Кояш) йөземнән (Җир) 280 метр ераклыкка урнаштырырга кирәк. Ә Кояш системасындагы планеталар тагын да ераграк торырга тиеш.

Мондый чагыштырулардан соң Кояш системасының гигант зурлыклары аңлашыла. Галактика үлчәмнәре белән чагыштырганда, безнең Кояш системасы урнашкан Киек каз юлының үлчәмнәре алай ук куркыныч зур да түгел. Якынча 250 миллиард йолдыз бар, кайберләре аларның Кояштан да күпкә зуррак. Спираль формасына охшаган галактиканың бер борылышында Кояш урнашкан. Галәм зурлыгы белән чагыштырганда, Киек каз юлы бик кечкенә. Галәмдә башка галактикалар да бар, әйтүләренә караганда, аларның саны 300 миллиардка җитәргә мөмкин.

Галәмдә күк җисемнәренең зурлыгын һәм гаҗәеп булуын күрсәтүче шушы мисаллар Бөек иҗатчының, Бөек көчнең кодрәтен, тиңдәшсез булуын күрсәтергә җитәдер. Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә кешеләрне бу хакта уйланырга өнди: "Сезне яңадан терелтү ансатракмы, әллә Күкне бина кылумы? Күкне Аллаһ яралтты. (Сезне яңадан терелтү Күкне барлыкка китерүдән дә ансатрак.) Күкнең биеклеген Аллаһ билгеләде. Аннан соң ул аны камил бер тәртипкә куйды" ("Нәзигать (Йолкып алу)" сүрәсе, 27-28 нче аятьләр).

*(Аднан ОКТАРның (Һарун ЯХЪЯ) "Һәркайда - гүзәллек" китабыннан өзекләр файдаланылды.)*

# Кабан арты мәчете ятим балаларны кунак итте

**Казанның Ислам динен кабул итүгә мең ел исемендәге Кабан арты мәчете Рамазанның беренче көнендә ук Дәрвишләр бистәсендәге балалар йортында тәрбияләнүчеләрне үзендә кунак итте. 70 балага вәгазь сөйләнде, шәмаил ясау буенча мастер-класс үткәрелде, аннан мәчет мәхәлләсе белән күмәк авыз ачу оештырылды. Җыен Кабан арты мәчете һәм "Зәкят" хәйрия фонды белән берлектә узды.**



Ятим балалар белән Кабан арты мәчете 2008 елдан эшли. Мәчет имамнары моны традициягә кертте һәм ул киләчәктә дә дәвам итәчәк. "Бу балалар безгә, без аларга ияләштек", - диләр монда.

Балаларны автобустан имам-хатыйб Сәетҗәгъфар хәзрәт Лотфуллин каршы алды. Баш имам балаларны мәчет-мәдрәсә биналары белән таныштырды. Сәетҗәгъфар хәзрәт мөфтият исеменнән балаларны Рамазан ае белән котлап, ураза тотуның файдасы турында сөйләде. Балаларга ТР мөселманнары Диния нәзарәте каршында эшләүче "Зәкят" хәйрия фондыннан бүләкләр тапшырылды.

Шуннан соң Марсель остаз балаларга милли каллиграфия дәресе үткәрде, шәмаил ясауда үз осталыкларын күрсәтте. Балалар зур теләк белдереп, үзләре дә шәмаил ясап караууда катнашты.

Балалар өчен ураза турында видеязма әзерләнгән иде. Шулай ук онлайн режимда мәчет мәхәлләсе һәм балалар Пенза татар-мөселманнары белән аралашты. Аерым алганда, Пенза мөфтиенең беренче урынбасары Хәмзә Еникиев, аның кызы Рамазан турында җыр башкарды. Авыз ачу вакыты иң җылы мөгамәләләрнең берсе булгандыр. Мәхәллә халкы балалар белән бергә янәшә утырып авыз ачты, милли тәгамнәр белән авыз итте. Ятим балалар белән киләсе ифтар мәҗлесе бу атнаның җомгасында уздырылачак.

# Гаиләбез ядкаре

**Һәр гаиләдә буыннан-буынга күчеп, кадерләп саклый торган ядкарь-истәлекләр бардыр, минемчә. Безнең гаиләдә исә иң кадерле ядкарьләрнең берсе - Коръән. Мин кечкенә чакта ук, өебезнең иң кадерле урынында пөхтә итеп төрелгән, еллар үтү белән бераз таушалган зур бер китапның саклануы турында белә идем.**

Әниемнең әлеге китапны саклап, хөрмәтләп тотуы үсә төшкәч мине тагын да кызыксындырды. Әле хәзер дә аның сүзләре колагымда яңгырый: "Кызым, бу безнең гаиләдә буыннан-буынга тапшырылып килүче иң изге Китап. Аны тәһарәтсез кулга алырга ярамый. Коръән бар нәрсәдән дә өстен. Шуңа да аны түбән урынга куярга рөхсәт ителми. Совет заманнарында дин тыелган вакытта да, әби-бабаңнар яшеренеп намазларын укыганда, бу Коръәнне дә кулларына алып укыганнар. Инде бу изге Китапны сез, сезнең балаларыгыз кадерләп сакларга тиеш". Әниемнең сүзләренә караганда, әлеге Коръәнгә бер гасырдан артык вакыт.

Әйе, чыннан да, бу китап мине үзенең серлелеге белән җәлеп итә иде. Шуңа күрә дә мин әбидән серле китапта нәрсә турында язылуын сорый идем. Ул миңа Коръән сүрәләре турында сөйли иде.

Коръәннең таушалган битләрен караганда, күңелгә ниндидер сихри көч, җылылык килгән кебек була. Әби-бабайларның намаз укуларын, мәчеткә баруларын күреп үскән бала буларак, мин дә күп кенә догаларны яттан беләм. Иншә Аллаһ, киләчәктә гарәп язуын өйрәнеп, Коръәнне уку дәрәҗәсенә ирешермен дигән хыялым да бар әле минем.

Безнең гаиләдә исә тагын бер ядкарь - әбинең әбисеннән калган чулпылар саклана. Алар 1837 елда чыгарылган көмеш тәңкәләрдән ясалган. Бәләкәйрәк вакытта үземнең озын толымнарыма әлеге чулпыларны тагып, көзге каршында бөтерелгәндә, әбиләр яшәгән чорга кабат кайткан кебек була идем. Үткән елларның хатирәсе булып, чулпыларның чыңлаган тавышларын ишетү минем өчен хәзер дә зур куаныч.

Бүгенге көндә дә без әлеге ядкарьләрне өебезнең иң күркәм урынында саклыйбыз. Алар барлык буыннар өчен дә бәяләп бетермәслек зур истәлек булып тора.

***Алия ЗӘЙДУЛЛИНА,***
***Лениногорск шәһәренең 2 нче урта мәктәбе укучысы***

**Сәхифә "Сабантуй" газетасы белән берлектә әзерләнде**

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 4 (147) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** 9409.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 26 июль көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).